ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.12.2017 Казан ш. № 5-53/тэ

«Таткоммунэнерго» республика җитештерү берләшмәсе» акционерлык җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга, җылы белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә) Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.12.2016 № 5-59/тэ карары белән билгеләнгән дәвамлы тарифларга 2018 ел өчен төзәтмәләр кертү хакында

«Җылы белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылы белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә һәм 2018-2019 елларга җайга салынулы оешмаларның планлы зарури тулай табышын тәгаенләштереп, 2018-2019 елларга җылылык энергиясенә (куәтенә) дәвамлы тарифларга төзәтмәләр кертү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Таткоммунэнерго» республика җитештерү берләшмәсе» акционерлык җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга, җылы белән тәэмин итүче башка оешмаларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә) 2017-2019 елларга тарифлар билгеләү турында» 15.12.2016 № 5-59/тэ карарының 1 нче кушымтасына, аны яңа редакциядә бәян итеп, шушы карар кушымтасына туры китереп, үзгәрешләр кертергә.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 01.12.2017 № 5-53/тэ карарына кушымта
«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 15.12.2016 № 5-59/тэ карарына 1 нче кушымта

# «Таткоммунэнерго» республика җитештерү берләшмәсе» акционерлык җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык энергиясенә (куәтенә) 2017-2019 елларга календарь буенча бүленгән тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, җайга салучы оешманың аталышы, тариф төре | Ел | су | Басым белән сайлап алынган пар | | | | Әче һәм редукцияләштерелгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см2 кадәр | 2,5тән 7,0 кг/см2 кадәр | 7,0дән 13,0 кг/см2 кадәр | югары 13,0 кг/см2 | |
| | Казан шәһәре | | | | | | | |
| 1 | «Таткоммунэнерго» республика җитештерү берләшмәсе» акционерлык җәмгыяте | | | | | | | |
| 1.1 | Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгәндә, – кулланучылар өчен | | | | | | | |
| | Бер ставкалы, сум/Гкал | 01.01.2017 башлап 30.06.2017 кадәр | 1181,73 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2017 башлап 31.12.2017 кадәр | 1231,36 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2018 башлап 30.06.2018 кадәр | 1231,36 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2018 башлап 31.12.2018 кадәр | 1256,10 | - | - | - | - | - |
| | | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 1256,10 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 1311,46 | - | - | - | - | -» |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге